Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

2 октябрь, 2024 ел № 2

Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Пимәр авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Пимәр авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 139 номерлы (2021 елның 13 декабрендәге 32 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Пимәр авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Пимәр авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Пимәр авылында. Гражданнар җыенын ике этапта үткәрергә:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 16 октябрендә 9.00 сәгатьтә Совет урамындагы 25А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Совет, Яшьләр урамнарында теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының икенче этабы 2024 елның 16 октябрендә 11.00 сәгатьтә Совет урамындагы 25А йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында үткәрергә. Җыенда катнашучылар исемлегенә Пионер урамында теркәлгән халыкны кертергә;

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2025 елда Пимәр авыл җирлеге Пимәр торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, көндезге уку формасы студентлары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары бер тапкыр бирелә торган түләүләрен (үзара салымын) түләүдән азат ителүе белән яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге

мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү;

- торак пункт территориясен төзекләндерү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Юныс авылында. Гражданнар җыенын 2024 елның 16 октябрендә 13.00 сәгатьтә Комсомольская урамы буенча 14 нче йорт янында уздырырга.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез 2025 елда Пимәр авыл җирлеге Юныс торак пункты территориясендә көндезге уку формасы студентлары, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары бер тапкыр бирелә торган түләүләрен (үзара салымын) түләүдән азат ителүе белән яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Пимәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Пимәр авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гыйматдинов